ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1569 «18» 12 2017 г.

2018 елга Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы мәгариф
оешмаларының норматив чыгымнарын
раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының «Мамадыш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 14 декабрендәге 1205 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2018 елга түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2. Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (Сергеев А.М.) түбәндәгеләр белән раслаган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2018 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2017 елның 22 сентябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы; әлеге карарның 1 пункты.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

4. Муниципаль район башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына әлеге карарны Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы И.М.Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
от ____________ № ________________
каарына кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Елына 1 тәрбияләнүчегә тотыла торган норматив чыгымнар сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | Шәһәр җирлеге | 86883 |
| | Авыл җирлеге | 88242 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | Шәһәр җирлеге | 132229 |
| | Авыл җирлеге | 136695 |

Җитәкче урынбасары В.И.Никитин